Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ

12+

№28 (79)

19 сентябрь 2013 ел

## • Вакыйгалар эзеннән

**16 СЕНТЯБРЬДӘ** ректор **И.ГАФУРОВ** катнашында **РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ** узды. Ул бүләкләү тантанасы белән башланып китте. Яшьләрне хәрби-патриотик тәрбияләүгә үзеннән зур өлеш керткәне, РФ Федераль куркынычсызлык хезмәтенең чик гаскәрләренә теләктәшлек күрсәткәне өчен, уку-укыту эшчәнлеге буенча проректор **Р.МИНЗАРИПОВ** III дәрәҗәдәге «Ватан сакчысына» ордены белән бүләкләнде. Контроль йөкләмәләрнең үтәлеше һәм 16-23 сентябрь аралыгында үткәреләчәк чаралар хакында административ эшчәнлек буенча проректор – аппарат җитәкчесе **А.ХАШОВ** җиткерде. Институт-филиаллар һәм факультетларның конкурентлылыгын арттыру буенча юл карталары һәм КФУ идарәсе органнарындагы үзгәрешләр белән икътисад һәм стратегик үсеш мәсьәләләре буенча проректор **М.САФИУЛЛИН** таныштырды. Проректор сүзләренчә, күпчелек структур бүлекчәләр юл карталарын тәкъдир иткәннәр, кайберләре хәтта яклаган да. Киңәш рәвешендә ул хезмәттәшләрен структур бүлекчә порталларының тутырылып барышына игътибар итәргә һәм халыкара фәнни совет булдыру мәсьәләсен җентекләп өйрәнеп бетерергә чакырды. Ректорат Н.И.Лобачевский ис. Математика һәм механика институтында «Математиканы мәктәптә һәм югары уку йортында укытуда инновацион технологияләр» дип аталган уку-эксперимент лабораториясен булдыру өчен тавыш бирде. Инновацион эшчәнлек буенча проректор **Н.КАШАПОВ** КФУның инжиниринг үзәген булдырудагы мөмкинлекләр һәм өстенлекләр турында җиткерде. Тышкы элемтәләр департаменты директоры **А.КРЫЛОВ** КФУга чит ил студентларын кабул итү нәтиҗәләре белән таныштырды: бүген бездә 1293 чит ил студенты белем ала.

• • • •

Шул ук көнне уку йортында **«XXI ГАСЫРДА ЕВРАЗИЯ ИНТЕГРАЦИЯСЕ: ПОТЕНЦИАЛЛАР, ПРОЕКТЛАР, КАРШЫЛЫКЛАР, КУРКЫНЫЧЛАР»** исемле VI Евразия фәнни форумы ачылды. Форумда катнашучылар XXI гасырда Евразия интеграциясе проблемасының фәнни-теоретик нигезен барлау, континентта төбәк интеграция мәсьәләләрен чишү юлларын эзләү белән шөгыльләнделәр.

• • • •

КФУның ИТИС Югары мәктәбе нигезендә «RuSSIR» мәгълүмати эзләнү буенча **ХАЛЫКАРА МӘКТӘП-КОНФЕРЕНЦИЯ ҮЗ ЭШЧӘНЛЕГЕН БАШЛАП ҖИБӘРДЕ**. Проект кысаларында катнашучылар Дублин университеты профессоры Гарет Джонсонның лекцияләрен тыңлыйлар. Алар сөйләмне компьютер ярдәмендә тануга багышланган. Чара 20 сентябрьгә кадәр дәвам итәчәк.

• • • •

**16 СЕНТЯБРЬДӘ** Фәнни эшчәнлек буенча проректор **Д.НУРГАЛИЕВ** Японияннең **РОТОБО КОМПАНИЯСЕ ВӘКИЛЛӘРЕ** белән **ОЧРАШТЫ**. Алар нефть эшкәртү буенча хезмәттәшлек итү мәсьәләсен күтәрде. Шулай ук ноябрьдә КФУ базасында шул өлкә буенча семинар уздыру турында да сүз алып барылды.

• • • •

**17 СЕНТЯБРЬ** көнне КФУ укытучылары һәм студентлары **А.БУТЛЕРОВНЫҢ ҺӘЙКӘЛЕНӘ ЧӘЧӘКЛӘР** куйдылар. Шушы көннәрдә аның тууына 185 ел тулды. Чараны Казан университетының Тарих музее оештырды.

• • • •

Шул ук көнне университетта кристаллар спектрокопиясе, күчмә һәм җирнең сирәк металларының активлашкан ионнарына бәйле **XV ХАЛЫКАРА ФЕОФИЛ СИМПОЗИУМЫ АЧЫЛДЫ**. Ул үз эшчәнлеген атна буе дәвам итәчәк.

• • • •

**18 СЕНТЯБРЬ** көнне КФУ җитәкчелеге **ГРИФФИТ УНИВЕРСИТЕТЫ** (Австралия) **ДЕЛЕГАЦИЯСЕ** һәм РФдагы **АВСТРАЛИЯ ИЛЧЕЛЕГЕ ВӘКИЛЛӘРЕ** белән **ОЧРАШТЫ**. Бу ике университетның беренче тапкыр күрешүе, шуңа күрә ул танышу характерында узды.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*




# Спорт дуслыкны ныгыта

17-22 сентябрь көннәрендә Ростов-на-Дону шәһәрендә Көньяк федераль университеты базасында III студентлар спорты фестивале уза.

Фестивальнең максаты шәхси спорт төрләрен үстерү түгел, ә команда ярышларын камилләштерү, тәҗрибә уртаклашу. Бүгенге көндә уку йортлары да, илебез дә спортны үстерүгә зур игътибар бирә, яшь спортчылар алдында зур мөмкинлекләр ача.

Медаль һәм кубоклар өчен барлыгы тугыз федераль университет көрәшәчәк. Алар: Казан (Идел буе), Балтыйк, Ерак Көнчыгыш, Төньяк (Арктик), Төньяк-Көнчыгыш, Төньяк Кавказ, Себер, Көньяк һәм Урал федераль университетлары.

Студентлар биш спорт төре буенча көч сынашачак: черлидинг «чир-данс», футбол, хатын-кызлар һәм ир-атлар арасында самбо һәм стритбол, пляж волейболы. Спорт төрләрен университетлар сайлаган һәм алар Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган.

Фестивальгә килгән командалар Көньяк федераль университетының көнбатыш кампусында яшәячәк, «Студентлар» туклану комбинатында ашаячак, шулай ук Иске Черкасскидагы казакъ традицияләре белән танышачаклар.

Ярышлар кичә башланып китте. Әйтергә кирәк: безнең университет спортчылары бик актив. Алар черлидинг буенча яхшы нәтиҗәләр күрсәтте. Башка уен төрләре буенча көч сынашу әле дәвам итә. Казан федераль университеты командасы фестивальдә сынатмас, дип ышанабыз. Алар уку йорты данын гына түгел, ә Россиянең спорт башкаласы булган Казаныбыз данын да яклый.

## • Бездә кунак бар

# «Күреп аралашуны алыштырып булмый!»

**Ләйсән ИСХАКОВА,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

КФУның Алабуга институтында икътисад һәм идарә факультетының 2-3 курс студентларына Чикаго профессоры Джон Эхерн өч көн буена лекция укыды. Ул КФУга уку йорты үсеше программасы буенча килгән. Казан студентларына лекцияләрне профессор өч ай буена укырга җыена.



**Ахыры 2нче биттә.**

• Уңыш сере

# «Театрга лицей белән йөрибез»

Әңгәмәдәш
**Алинә САДЫЙКОВА**

Яңа уку елыннан Казан федераль университеты структурасында тагын бер бүлекчә барлыкка килде. Сүзем Н.И.Лобачевский исемендәге лицей турында. Биредә миллилек һәм татар теленең ихтыяҗын арттыру идеясе белән янып йөрүчеләр байтак. Директорның милли мәсьәләләр буенча урынбасары, югары категорияле укытучы Фәнис Мөхәмәтшин да әлеге Казанда кайный һәм бу процессны алга җибәрү өчен күп көч куя.



**– Фәнис Мөхәммәтгалиевич, сезне укытучы һөнәрен сайларга нинәр этәрде?**

- Һәр кешенең яраткан, күңеленә якын төбәге була һәм профессияне сайлаганда да шул төбәктә яшәгән кешеләрнең йогынтысы тими калмыйдыр. Минем белән дә шулай булды. Иң беренче чиратта, бу – туган тел һәм әдәбият укытучысының миндә күренекле классик язучыларның әсәрләренә мәхәббәт хисе уятуы. Алга таба тарихка бәйле китаплар күңелемдә урын алды. Тагын бер фактор бар: 90 елларда безнең милли күтәрелеш чоры башланды. Үзебезнең тарих, әдәбият белән тирәнтен кызыксыну «модага кереп китте». Шул күтәрелеш дулкыны белән бергә, мин дә 1995 елда университетка укырга кердем. Алга таба минем өчен бу белемнәрнең генә аз булуына төшендем һәм гыйлем алуымны аспирантурада дәвам иттем. 2007 елда Фәһимә Хисамова җитәкчелегендә диссертация якладым. Лицейда исә 2004 елдан эшли башладым.

**- Казан федераль университеты лицей өчен нинди мөмкинлекләр ача?**

- Быелгы уку елыннан без яңа статус алдык - Казан федераль университетының бүлекчәсенә әверелдек. Моның уңай яклары бик күп. Беренчедән, бездә университет галимнәре күпләп эшли, ә бу укучыларда фән белән кызыксыну мөмкинлеген арттыра дигән сүз. Икенчедән, университетның фәнни китапханәсе дә хәзер безнең өчен һәрвакыт ачык. Һәр укучы анда барып, теләгән китап белән таныша ала. Өченчедән, быелдан башлап, 9 сыйныфлар татар теленнән имтиханны яңа формада бирәчәк. Укучыларның әзерлеген арттыру максатыннан, лицейда махсус курслар оештырыла. Алар, дәресләрдән тыш, атнага 2 сәгать уздырыла. Боларның барысын да тормышка ашыру федераль университет бюджетына кертелгән.

**- Лицей укучыларының татар теленә ихтыяҗы ни дәрәҗәдә һәм аларның телгә карата мөнәсәбәтләре тагын да яхшы якка үзгәрсен өчен, нинди чаралар күрәсез?**

- Телгә ихтыяҗ төрлечә бара. Теләп укучылар бар һәм мин аларны күп дип әйтер идем. Безгә балалар 7 сыйныфка килә. Һәм биредәге уку алдагы елларда өйрәнгән материал нигезендә дәвам иттерелә. Кайбер балалар белән индивидуаль эшләп, аларны татар теленә якынайтырга тырышабыз. Республикабызда шундый проблема күзәтелә: татар балалары ана телен белмиләр. Бу әйбер мәктәпкә, балалар бакчасына гына да кайтып калмый, ул гаиләдән килә. Әни кеше өйдә бала белән нинди телдә сөйләшсә, баланың теле нинди телдә ачылса, ул шул тел белән бара инде. Бу очракта әти-әниләргә мөмкин кадәр ана теленең әһәмиятен аңлатырга кирәк дип саныйм. Чараларга килгәндә, безнең лицей күбрәк төгәл фәннәргә: физика, химия, биологияләргә тартым. Шуңа да карамастан, без ана телен, татар телен укытуны милли тәрбия аша алып барырга тырышабыз. Мәсәлән, рус балаларын тел белән кызыксындырып, фәнгә кертеп җибәрү өчен, аларны үткән тарихыбыз, әдәбиятыбыз, күренекле кешеләребез белән таныштырабыз. Аннан соң инде әкренләп темаларга кереп китәбез. Укучылар арасында татар телендәге әдәби әсәрләрне оригиналда укучылар да бар.

**- Лицейда милли мәсьәләләр ничегрәк куелган?**

- Татар халкының бик күп милли бәйрәмнәре бар. Без аларны лицейдә уздырабыз. Мисал өчен, татар ашлары көне. Гадәттә, ул февраль яисә март айларында була. Укучылар үзләре милли ризыклар әзерләп киләләр. Бу процесс презентация формасында бара. Алар анда милли ризыкны ничек пешергәннәре турында сөйлиләр, биюле-җырлы өлеш тәмамланганнан соң, бергә утырып чәй эчәләр. Район, шәһәр күләмендә уздырылган конкурсларда һәрдаим катнашып торабыз. 2009-2010 уку елында шәһәркүләм «Татар кызы» конкурсында бездә укыган кыз Ширин беренче урынны яулады. Еш кына музейларга йөрибез һәм, практика күрсәткәнчә, анда бигрәк тә рус балаларында телгә һәм мәдәнияткә кызыксыну уяна. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт драма театры белән бәйләнештә торабыз. Бу 2009 елда бер проект булып башланып киткән иде, хәзер инде ел саен үткәрелә торган чарага әверелде. Укучылар яңа чыккан татар спектакльләренең премьераларына йөриләр. Бу лицей күләмендә оештырыла, бер бала да читтә калмый. Аның өчен безгә махсус көн билгелиләр. Һәм менә спектакльне караганнан соң, укучылар әлеге әсәргә бәяләмә, рецензия язалар. Бу конкурс формасында оештырыла. Аларның рецензияләрен катнашучы актерлар, режиссер укып, урыннарны билгелиләр. Иң яхшы эш дип исәпләгәннәренә истәлекле бүләкләрен бирәләр. Укучылар монда бик теләп катнашалар. Шунысын әйтергә кирәк: лицей директоры Елена Скобельцына, әлеге чараларны уздырганда, һәрвакыт безгә бик теләп ярдәм итә һәм бу аның хуплавы белән башкарыла.

*✦ Зур потенциаллы укытучыларның укучылары да үзләренә охшаган. 11А сыйныфында белем алучылардан: «Лицейда татар телен укытуны ничек бәялисез?» - дигән сорауга түбәндәге җавапларны алдык:*

***Володя Сухолев, татар теленнән олимпиадаларда җиңүче:*** *«Минемчә, татар теленә мөнәсәбәт, башка мәктәпләр белән чагыштырганда, безнең лицейда шактый яхшырак. Ләкин республика күләмендә бу мөнәсәбәт тиешле дәрәҗәдә түгел. Кызганыч, татар теле икенче рәсми тел булуга карамастан, бөтен бала да аны теләп үзләштерми. Безнең уку йортыбызда исә, һәр теләгән кеше татар телен тирәнтен өйрәнә ала, укытучыларыбыз моның өчен бар көчләрен куялар».*

***Айгөл Хәкимова:*** *«Безнең татар теле укытучысы һәр дәресне кызыклы һәм мавыктыргыч итеп әзерли. Ул безне дә уйларга, фикерләребезне җиткерергә өйрәтә, татар халкының бай тарихы турында кызык итеп сөйли. Мөгаллимнәр безне белемле итү өчен бик тырышалар».*

• Бездә кунак бар

# «Күреп аралашуны алыштырып булмый!»

**Башы 1нче биттә.**

Джон Эхерн рус телендә начар сөйләшә, шуңа да лекцияне Алабуга институтының чит телләр факультеты укытучылары тәрҗемә итеп барды. Профессор «Бухгалтерлык исәп-хисабына кереш», «Бурыч җаваплылыгы», «Икътисади өлкәдә караклык» дигән темаларга чыгыш ясады. Джон Эхерн Америка һәм бездәге студентлар арасында артык аерма күрми: аларда да, бездә дә бик яхшы, яхшы укучылар һәм ялкаулар бар. Чикаго профессоры Россия укытучыларына атналык сәгатьләр күләмен кыскартырга киңәш итте, чөнки атнасына 36 сәгать укыту бик авыр! Көне буе укыту хәлне ала. Үзе исә атнасына нибары 12 сәгать дәрес бирә икән. Хәзер аларын да дистанцион рәвештә алып бара. Джон Эхерн лекцияләре он-лайн яздырыла. Шулай да, профессор җанлы аралашуны берни белән дә алыштырып булмый, дигән фикердә тора.

Джон әфәндегә Алабуга үзенең классик биналары белән ошаган. Шуны да билгеләп узарга кирәк: профессорның Россиягә беренче мәртәбә генә килүе түгел. Ни сәбәпле Россияне якын күрүе хакындагы сорауга ул: «Биредә бик мөлаем кешеләр яши!» – дип җавап бирде. Эхерннар гаиләсендә күпләр шул фикердә. Илебезгә профессорның хатыны да килгән. 1995 елда, Казанга беренче тапкыр килгән чагында, Джон әфәнде улы Патрикны да ияртә. Шуннан соң Патрик, Чикаго университетын тәмамлап, Казанга күчеп килгән һәм күпмедер вакыт КДТУда инглиз телен дә укыткан.

*Алабуга матбугат үзәге ярдәме белән эшләнде*

• Безнең канат

КФУның Н.И.Лобачевский исемендәге лицеена ел саен яңа укучылар килә. Быелгы уку елы да искәрмә түгел.

# «Гаилә»без серләре

**Наталья ПАНКРАТОВА,**
11 С сыйныфы укучысы

Уку елы башланды, тормыш кайный... Лицейда яңа йөзләр дә артты. Ә аларны күреп алу әллә ни авыр түгел. Тик шулай да калганнардан нәрсә белән аерыла соң алар? Әлбәттә, яңа укучылар өчен зур бинабызда кабинетларны табу авыр.



Лицей – ул бик зур, тату гаилә. Гаиләбезгә килеп кергән әгъзалар үзләрен яхшы хис итсен өчен, без, өлкән сыйныф укучылары һәр елны тренинглар уздырабыз. Уеннар, җыр-биюләр ярдәмендә без дуслык күперен ныгытабыз.

Тренингның беренче этабы булып, «Лицей биюләре» тора. Барыбыз бергә бер бию өйрәнергә тиеш. Нәтиҗәсе күз алдыбызда: һәр иртә дәресләр башланыр алдыннан без ул биюне бергәләп башкарабыз.

Икенче этапны тормышка ашырганда, һәр укучы бәхет кошын ясауга үз өлешен кертте. Без аны уч төбен кәгазьгә төшереп ясадык.

Яңа дусларыбыз «Лицей җыры» өлешен дә бик яратты. Түгәрәк булып утырып, гитарага җырладык.

«Лицей этикасы»н өйрәнү дә укучыларга ярдәм итми калмас, чөнки биредәге тәртипне бозмаска, кагыйдәләргә буйсынырга, традицияләрне сакларга кирәк.



Лицейдагы «туганлык» хисләрен дә ныгыттык. Һәр яңа укучы үзе белән якыннан таныштырды, тагын да ныграк берләшү өчен төрле биремнәр башкарды.

Тренингның кульминацион ноктасы - лицейчы антын кабул итү. Укучылар мөгаллимнәр биргән белемне яхшылап үзләштерергә һәм ашханәдә туйганчы ашарга сүз бирделәр.

Шуны әйтергә телим: безнең гаиләнең дуслыгы нигезе менә шулай салына.

• Н.И.Лобачевкий исемендәге лицей Россиянең иң яхшы 25 мәктәбе рәтенә керде. Ул хәтта Мәскәүнең кайбер мәктәпләрен дә уздырды. Бу, әлбәттә, укытучылар коллективы, укучылар, аны тәмамлаучылар хезмәте. Мәскәүнең өзлексез математик белем бирү үзәге тикшерену вакытында төп йомгакны олимпиада, БДИ нәтиҗәләре буенча ясый. Илебезнең 77 төбәгеннән 500 мәктәп кергән рейтинг төзелә. Татарстаннан 19 мәктәп шул исемлеккә керә, ә лицей беренче егерме бишлеккә эләгә. Бу җиңү белән белем йортының һәр укытучысын, укучысын, хезмәткәрен ихластан котлыйбыз!

• Кечкенә галимнәр

# Беренче ботка

Сәхифәне **Алинә САДЫЙКОВА** әзерләде

Искәндәр Аязовичны һәр студент һәм укытучы житди кеше буларак белә. Әмма ул да кайчандыр студент булган, ә студентлар, билгеле инде, шук һәм күңелле халык...

«Без, студент чакта, археографик экспедицияләргә йөри идек – татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә борынгы кульъязма, китаплар эзләп, җыеп йөри идек. Анда зур булмаган, 7-8 кешедән торган төркем булып оешып, палаткаларыбызны алып чыгып китә идек. Бервакыт Кострома өлкәсендә миңа ботка пешерергә туры килде. Анда дежурныйларны билгелиләр һәм, теләсәңтеләмәсәң дә, йөкләнгән вазифаны башкарасы иде. Ә мин – шәһәр малае – бу вакытка кадәр ашарга пешереп караган кеше түгел. Шулай да, үземне башкалар янында сынатмас өчен, бу эштән баш тартмадым. Пешекчелек сәләтләремне күрсәтергә дип йокыдан уянып, палаткадан чыкканда, башкалар әле йоклый иде. Мин аларның уянуларына ботка әзерләп куярга тиеш инде. Ә тышта яңгыр ява, каты җил исә, җитмәсә, учагын да кабызып булмый. Ниһаять, учакны кабыздым һәм ботканы пешәргә куеп җибәрдем. Аның кайнап чыкканын сабыр гына көтеп утырам һәм, менә пешеп җитте, дигәндә генә учак өстендәге бераз авышкан кәстрүлне рәтләп куярга уйладым. Тик минем ниятем барып чыкмады: кәстрүлем ауды һәм боткам җиргә, чирәм өстенә түгелде. Минем бәхетемә, моны беркем дә күрмәде һәм мин, берәрсе уянганчы дип, шул түгелгән ботканы кашык белән тиз генә кәстрүлгә кире тутырып куйдым. Әлбәттә, аның бер өлеше җирдә калды инде. Ул вакытта безнең җитәкчебез остазым, бөек тарихчыбыз Миркасыйм абый Госманов иде, ул шушы экспедицияләрнең төп оештыручысы булды. Минем теге ботканы ашаганда, ул: «Нишләптер бу боткада ком бар шикелле», – дип әйтеп куйды. Сизәм: ул ботканың җиргә ауганын, минем аны кире тутыруымны күреп алган булган... Шулай да, ул вакытта бөтен кешенең бик ашыйсы килү сәбәпле, аның сүзләренә артык игътибар биреп тормадылар. Мин дә ашадым инде шул ботканы, иртәнге ашсыз калып булмый бит! Бу вакыйганы искә алып, Миркасыйм абый һәрвакыт көлә иде».

Шушы экспедицияләргә йөргәндә, татар язмышына битараф булмауның бик әһәмиятле икәнлегенә дә төшендек».


1979 ел



*Татарларда горурлык хисен булдырып, һәр кешенең миенә «Без – ҹзгә, бер илдә торсак та, бер хокуклы булсак та, без, татарлар, ҹзебезчә яшибез», – дигәнне сеңдерергә кирәк. Без – бөек халык дип йөрмәгез, шыпырт кына бөеклегегезне гамәлегез аша күрсәтегез, исбат итегез.*

• «Авылдагы» хәлләр

Универсиада авылында яшәүче студентлар Универсиада авылы һәм башка җитәкчеләр белән танышуларын дәвам итә. Шундый очрашуларның берсе 17 сентябрь көнне Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты студентлары яши торган 18нче йортта да уздырылды.

# Танышу дәвам итә

**Раил САДРЕТДИНОВ,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Очрашуга Универсиада авылы мэры киңәшчесе **Илгиз Абдуллин** һәм Казан (Идел буе) федераль университеты студентларын тулай торак белән тәэмин итү бүлеге җитәкчесе **Ирина Бабайкина** килгән иде.

Иң башта Илгиз Абдуллин Универсиада авылында хөкем сөргән тәртипләр турында искәртеп үтте. Тәртипләр гади, үтәмәслек түгел. «Универсиада Казаныбызга күп нәрсә бүләк итте. Универсиада авылы да шул бүләкнең берсе. Хәзер инде ул Россиядә студентлар яши торган иң яхшы кампус дигән исемгә лаек. Биредә 3 ел дәвамында гадәттән тыш хәлләр булганы юк. Алга таба да булмас дип өметләнеп калам. Күбегезнең иске тулай торакларда булганы, андагы яшәү шартларын күргәнегез бардыр. Без бүген бөтен Рәсәй студентларына тыныч, ватуҗимерүләрсез яшәп булганлыгын үрнәк итеп күрсәтәбез», – диде мэр ярдәмчесе үз чыгышында. Аннан ул Универсиада авылы территориясенә сәламәт яшәү рәвеше территориясе статусы бирелү турында да әйтеп үтте. Димәк, Универсиада авылы территориясендә тәмәке тарту, спиртлы эчемлекләр эчү, наркотиклар куллану катгый тыела һәм кагыйдәләрне бозган студент Универсиада авылыннан гына куылып калмый, ә бөтенләй тулай тораксыз кала дигән сүз. Элек ничектер иске тулай торакларда урын тапсалар, быел андый мөмкинлек юк, чөнки иске «общагалар» да студентлар белән шыплап тулган.

Ирина Бабайкина исә, үз чыгышында студентларны тулай тораклы итү турында, бу процессның ничек баруы хакында тәфсилләп сөйләде. Барысын да гадәттән тыш хәлләрсез, тыныч, матур яшәргә чакырып калды. Икенче елга да исән-сау шушы урында очрашырга насыйп булса иде, дигән зур теләген белдерде.




• Син һәм мин=БЕЗ!

# КФУ - «Яхшы кешеләр иле»

**Ләйсән ГАЛИУЛЛИНА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Студент чаклар – тормышның иң кызыклы вакыты. Ул чорны йоклап та, җырлап-биеп, уйнап-көлеп тә яисә изге гамәлләр кылып та уздырырга мөмкин. Соңгылар арасына «Яхшы кешеләр иле» исемле ярдәм итү үзәгенә йөри торган студентларны кертер идем.

Аларның төп максатлары – кешеләргә булышу. Бирегә беркемне дә мәҗбүри китермиләр. Бу үзәкне оештыручылар да, аңа йөрүчеләр дә – студентлар. «Яхшы кешеләр иле»н Ришат Ярмөхәммәтов дигән студент җитәкли. Бар җирдә дә актив егет башка кешеләр тормышына, алар кичергән авырлыкларга битараф кала алмый. Ул үзәк өчен төрле проектлар төзи, студентлар булыша алырлык эшләр таба. Ә алар бик күп: шәһәр күләмендә уза торган бәйгеләрдә катнашу, сугыш ветераннарына булышу, авыр гаиләдә үскән балаларга ярдәм итү.

Әлеге үзәккә күбесенчә 1-3 курсларда укый торган студентлар йөри. Аларның һәркайсы үзенчәлекле. Җитәкче тарафыннан эш йөкләгәнне көтеп тормыйлар, ә үзләре төрле ярдәмгә мохтаҗларны эзләп табып, аларның хәленә керергә тырышалар.

Активистларның берсе **Земфира Билалова** сүзләренә караганда, алар катнашкан һәр вакыйга бик кызык һәм истә калырлык булып үтә. Күңел биреп эшли торган проектларының берсе – «Язгы яхшылык атнасы»н уздыруда Татарстанның бөтен волонтёрлары катнаша икән. Бердәм булу хисе аларга тагын да көч өсти. «Мондый чаралар уздырганда, син бер үзең генә түгеллекне аңлыйсың. Яшьләр берләшсә, тауны да урыныннан кучереп куярга мөмкин икән!» – ди Земфира. Бу атналык кысаларында өлкәннәргә булышу, өйләрен җыештыру, кибеттән, даруханәдән кирәк-яраклар алып кайту кебек эшләр башкарыла икән. Шулай ук донорлык акциясен үткәреп, бик күп авыруларга ярдәм иткәннәр.

Үзәк активистлары әтиәнисез калган сабыйларга да бик теләп булыша. Алар өчен төрле концерт-тамашалар куялар, спорт ярышлары үткәрәләр, бүләкләр өләшәләр. Студентлар табигатьне саклау турында да онытмый. Алар һәр ел саен агачлар утырталар. Йортсыз калган хайваннарга да ярдәм итә яшьләр.

Үзәкне үз итүчеләр саны көннән-көн артып тора. Яхшылык эшләргә беркайчан да соң түгел. Изге эш җирдә ятмый, дип юкка гына әйтмиләр. Бүген мин авыр хәлдә булсам, иртәгә син шундый хәлгә төшәргә мөмкин. Шуңа күрә кулыбыздан килгәнчә бер-беребезгә ярдәм итсәк иде. «Яхшы кешеләр иле»ндә «яшәргә» теләсәң, рәхим ит. Анда гражданлык та, прописка да, акча да кирәкми. Синнән бары тик киң күңелле, ярдәмчел, ягымлы, аралашучан булу гына таләп ителә.









• Әдәби сәйләннәр



БҮГЕН СЕЗНЕ ЯШЬ ИҖАТТАШ ДУСТЫБЫЗ - ГАММӘВИ КОММУНИКАЦИЯ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ФӘННӘР ИНСТИТУТЫ СТУДЕНТЫ ГҮЗӘЛИЯ ГЫЙНИЯТУЛЛИНА ИҖАТЫ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРАБЫЗ. УЛ БАШКОРТСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨТЕШЛЕ РАЙОНЫ БОРГЫНБАШ АВЫЛЫНДА ТУГАН. ГҮЗӘЛИЯ ХАЛЫК БИЮЛӘРЕН БИК ЯРАТА. БУШ ВАКЫТЛАРЫНДА ШИГЫРЬЛӘР ДӘ ЯЗГАЛЫЙ, СПОРТ БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНӘ. XXI ГАСЫР ЯШЬЛӘРЕНДӘ ТУГАН ТЕЛГӘ САФ МӘХӘББӘТ УЯТУ, ТЕЛЕБЕЗНЕ БАЕТУ ТУРЫНДА ХЫЯЛЛАНА.

# Адым саен елмаю...

Өлкән яшьтәгеләрдән без еш кына, гомер кыска, кадерен белеп яшәгез, дигән сүзләр ишетәбез. Әлегә кадәр аларга әллә ни игътибар бирми идем. Нишләп кыска булсын инде, алда күпме еллар һәм юллар, өр-яңа ачышлар, танышлар, эш-гамәлләр көтә.

Чыгарылыш сыйныфына аяк басып, соңгы тапкыр беренче кыңгырау тантанасында катнашканнан соң, ничектер ямансу булып китте. Мин мәктәбем, дусларым, белем үрләрен яуларга ярдәм иткән кадерле укытучыларым белән саубуллаштым бит?! Кайчан гына, күбәләктәй талпына-талпына, беренче сыйныфка килгән идем. Вакыт менә ничек тиз үтә икән! Димәк, һәр көннең, һәр мизгелнең кадерен белеп, авырлыклардан курыкмыйча, саф намус белән яшәргә кирәк. Ә еллар агышы мәгънәле, тормыш матур булсын өчен, күбрәк елмаерга, бер-беребезгә карата игътибарлы, ихтирамлы булырга кирәк.

Елмаюның көче, тәэсире турында күп бәхәс куертырга мөмкин. Көлеп торган кешеләрнең йөзеннән сихри нур бөркелгән сыман. Алар белән аралашуы рәхәт: сине ихлас тыңлыйлар, киңәш бирәләр, авыр чакта юаталар, җаныңа дәва табалар. Минем тагын бер нәрсәгә игътибар иткәнем бар. Гел елмаеп-көлеп тора торган кешедән дә сылу зат юктыр сыман. Шул ук вакытта йөзендә елмаю яисә сөйкемлелекнең әсәре дә булмаганнардан боз салкыны сирпелә, җанны туңдырырлык карашыннан ничек качарга белмисең.

Ашыга-ашыга чапкан гомер агышында аралашкан танышлар, дусишләр күңелендә матур хатирәләр калдырыйм дисәң, мөмкин кадәр ешрак елмаерга, ихлас киңәш-табыш итәргә кирәк, дип уйлыйм. Дөнья гел шатлыклардан, уңышлардан гына тормый, югалтулары, әрнү-газаплары да җитәрлек. Ялгыш сүз әйтеп, сине рәнҗетсәләр яисә үзеңнән урынсыз сүз ычкынса, мөмкин кадәр тизрәк аңлашу юлларын эзләргә кирәк. Ә инде уртак фикергә килгәч, елмаеп саубуллашудан да яхшысы юктыр.

Арып-талып ял итәргә яткач, көн дәвамында булган вакыйгаларны барларга яратам. Кайда ялгышлык җибәрдем, кемгә катырак бәрелдем, ярдәмемә мохтаҗларга кул суздыммы? Төрле чаклар була икән. Иртәгә, һичшиксез, бүгенгәдән яхшырак булырга, елмаю бүләк итәргә тырышырмын дигән уйлар белән йокыга талам.

Ә иртән әнием елмаем уятса, әтием аркамнан сөеп хәерле юл теләсә, үземне бәхетле тоям. Дәрестә укытучым мактап яхшы билге куйса, тәнәфес вакытында ахирәтем белән серләшсәм, көлә-көлә берәр вакыйганы искә алсак, күңелләр күтәрелә.

Димәк, яшәү ямен тояр өчен, изгелекләр кылырга, ешрак елмаерга кирәк.

• Акылы-каралы дөнья

# «Смайлик»лы чынбарлык

Ләйсән ИСХАКОВА,
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты



БҮГЕН БӨТЕН ҖИР ШАРЫНДА СМАЙЛИК КӨНЕН БИЛГЕЛӘП ҮТӘЛӘР. КОМПЬЮТЕР АША АРАЛАШКАНДА КУЛЛАНЫЛА ТОРГАН БУ СИМВОЛНЫҢ КИЛЕП ЧЫГУ ТАРИХЫ НИДӘН ГЫЙБАРӘТ СОҢ? ӘЙДӘГЕЗ, ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕНӘ МӨРӘҖӘГАТЬ ИТИК ☺.

Беренче мәртәбә электрон аралашуда елмаюны белдерер өчен, бер-бер артлы килә торган махсус билгеләр: ике нокта, дефис һәм җәя файдалануны 1982 елда Карнеги-Меллон университеты профессоры **Скотт Фалман** тәкъдим итә. Әлеге яңа символны «смайлик» дип атый башлыйлар, чөнки, инглизчәдән тәрҗемә иткәндә, **smile «елмаю»** дигәнне аңлата. Шул рәвешле, смайл электрон лексиконны баетып кына калмыйча, кешеләргә компьютер аша аралашканда, хис-кичерешләрне төгәлрәк җиткерү өчен, менә дигән мөмкинлек тә тудыра.

Баксаң, Фалманның виртуаль тактага беренче мәртәбә смайл файдаланып язылган хаты һаман да саклана икән. Әлеге такта ул чакларда бүгенге интернет-форумнарны алыштырган һәм университет хезмәткәрләре арасында төп аралашу чарасы булып хезмәт иткән. 30 ел дәвамында смайлның токымнары арткан: елмаюны гына түгел, моңсулык, усаллык, көлү, елау, үбү һ.б кичерешләрне, эш-гамәлләрне белдергән символлар барлыкка килгән.

Бүген исә электорон аралашуны смайликлардан башка күз алдына китерүе дә кыен. Алай гына да түгел, смайликсыз язылган хат ничектер коры, дорфа булып тоела хәтта. Әлеге билгеләр виртуаль аралашу вакытында әңгәмәдәшнең тавыш интонациясен һәм мимикасын җиткерергә сәләтле. Кайвакытта кешенең тавыш һәм йөз үзгәреше сүзләргә караганда да мөһимрәк булырга мөмкин, шулай бит?

Шуңа да смайликлар бүген бик популяр. Алар әңгәмәдәшнең кәефен яхшырак аңларга ярдәм итә. Өстәвенә, смайликлар үзләре дә кызык һәм үзеннән-үзе кәефне күтәрергә сәләтле. Хәзер смайлны Интернет челтәрендә генә түгел, СМС-аралашуда да иркен кулланалар.

Смайлның заманча кыяфәтен исә (ягъни менә шушы ике noктадан торган күз һәм елмаюны белдергән җәяне үз эченә алган түгәрәкне☺ ) 1963 елда ук америка рәссамы **Харви Болл** уйлап тапкан була һәм рәсемгә төшерә. Ул чакта Америкада эре иминият компанияләрен берләштерү башлана. Әлеге процесс бик әкрен һәм шактый катлаулы барган. Шул сәбәпле, әлеге компаниядә эшләүче хезмәткәрләр гел моңсуланып, кайвакыт хәтта ачулы йөри башлаган. Шуңа бу компания хезмәткәрләренең хезмәт рухын, кәефен күтәрергә тырышалар, чөнки, клиентлар белән эш йөрткәндә, елмаеп сөйләшү зарур була. Нәкъ менә шул максат белән, иминиятчеләр рәссам Харви Боллга мөрәҗәгать итә. Алар аннан ниндә булса күңелле, кызык символ уйлап табуын үтенәләр. Һәм бу үтенеч бик тиз арада кабул да ителә. Бу эшкә рәссам нибары 10 минутын сарыф итә. Бу төрдәге смайликларның беренче сериясе менә шундый сары төстәге значоклар формасында эшләнә. Аларны компания хезмәткәрләренә һәм клиентларга тараталар. Бу логотиплар шактый уңыш казана, шуңа күрә аларны 10 меңнән артык итеп бастыралар. Узган гасырның 70 елларында исә бу график рәсемгә әле күтәренке рухлы «Хәерле көннәр!» дигән слоган да өстәлә. Смайл күп төрле товарларга төшерелә башлый һәм аларның сатылуын күпкә арттыра.

Хәзер смайликларның нинди генә төре юк. Бу гаҗәп тә түгел, чөнки бүген алар динамик рәвештә үсеш кичерә торган тулы бер системаны хасил итә.

**Иң кызыклыларын сезгә дә тәкъдим итәбез.**


:( - моңсулык
:-| - уйга бату яки битарафлык
:-D яки :D – көлү
*O* яки *_* - соклану
XD яки xD – күзне кыскан килеш көлү
:-C яки :C – бик каты күңел төшү
:-/ яки :-\ - ризасызлык яки үпкәләү
:-0 яки :O – гаҗәпләнү
:-e – күңел кайту
8-O яки =-O – шаккату
:-[ - уңайсызлану
:-D – әче итеп көлү
;-) яки ;) – күз кысу
:-P яки :-p – тел күрсәтү
:-*- үбү
:* - елау
:-@ - ачуланып кычкыру
:-X – авызны биктә тоту, сер чишмәү
{} –кочаклау

• Мәсьәләгә бер караш

# Без экстрим яклымы?

Зәлия ЛАТЫЙПОВА,
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

ТИРӘ-ЮНЬДӘГЕЛӘРНЕ ҮЗЛӘРЕНЕҢ ЭШ-ГАМӘЛЛӘРЕ БЕЛӘН ШАККАТЫРУ ЗАМАНА ЯШЬЛӘРЕНЕҢ БЕР ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ. БАШКАЛАРДАН АЕРЫЛЫП ТОРУ, ИНДИВИДУАЛЬЛЕККӘ ИРЕШҮ ӨЧЕН НИЛӘР ГЕНӘ КЫЛАНМЫЙ АЛАР?!



Шундый үзенчәлекле яшьләрне берләштергән гадәти булмаган төркемнәр дә бихисап. Инде карага манылып йөргән готларга, сәер эмоларга, шау-шулы металлистларга ияләнеп беткән идек кебек. Әле бер көнне яшь кенә егет тагын бер яңа агым турында сөйләде. Русча әйткәндә, **«чудаклар»** (ингл. **«Jackass»**) итеп атыйлар алар үзләрен. Бу – үзенә күрә бер күңел ачу чарасы. Аларның төп максаты – тирә-юньдәгеләрне шаккатыру, аптырату. Jackass – ул яшьләрнең күңел ачу, юмор, адреналин алу өчен берләшүе. Биредә адреналин яратучы яшь каскадерлар катнашында төрле чаралар үтә.

**Саша** белән без очраклы рәвештә таныштык. Карап торышка гади генә егет, башкалар кебек үк киенгән. Ләкин сүзләре, фикер сөреше башка. Аның сүзләре белән әйтсәк, бу төркемгә ул «кызык эзләп» килә. Төркемнең үз кануннары бар – беркайчан да бер-береңне кимсетмәскә, һәр кешенең фикерен хөрмәт итәргә. «Канун»нар үтәлмәгән очракта, аерым җәзалар каралган. Хәтта төркемнән куарга да мөмкиннәр. «Кешеләрнең нәрсә уйлавы безнең өчен мөһим түгел. Бары тик шундый кешеләр генә соры көннәргә нинди дә булса яңалык кертергә сәләтле», – ди Саша.

2002 елда зәңгәр экраннарга чыккан «Чудаки» фильмын әле күпләрегез хәтерлидер. Менә нәкъ шул кинодагыча, егетләр «трюклар», гадәти булмаган куркыныч күнегүләр ярдәмендә үзләренең ялын үткәрә, адреналин ала. Сашага исә кыялардан сикерү аеруча ошый икән. «Җәрәхәтләр турында оныттым инде. Бәрелмәгән, кара көймәгән җирем юк. Бер ай хастаханәдә дә ятып чыктым. Ләкин бу гына мине туктата алмый», – ди ул. Шушы сүзләрдән соң аптырап калдым. Минем яшьтәшләрем җәмгыятьтә камилләшүнең менә нинди юлын сайлый икән!

Икенче бер «чудак» – **Денис** бу шөгылен ташлаган. Ни өчен, дигән соравыма ул: «Үземнең нинди акылсыз булуымны хәзер генә аңлыйм. Вакытны җилгә очыру, сәламәтлекне бетерү бит ул. Ярый әле дусларым дөрес юл күрсәтте», – дип, фикерләре белән уртаклашты.

Мондый гадәти булмаган төркемнәргә җәмгыять, гомумән, каршы. Кемнән генә сорасаң да: «Пычрак, әдәпсез бит алар», – дип җавап кайтаралар. Яшь вакытта чыннан да башкалардан аерылып торасы, текә күренәсе килә. Ләкин бит адреналин алу өчен, нәкъ менә таудан сикерү я, алар фикеренчә, рухи яктан камилләшү өчен, тәнне булавкалар белән тишкәләү мәҗбүри түгел. Минемчә, мондый төркемнәр – җәмгыятьтә үз урыннарын таба алмыйча җәфаланучы, әти-әни игътибарыннан читтә калган, дөрес тәрбия алмаган яшьләр. Тирә-юньдәгеләргә, якыннарыбызга игътибарлырак булсак иде. Шул юл белән без аларны ялгыш адымнар ясаудан саклап кала алырбыз, дип ышанасы килә.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.